| Совет Абалачевского сельского поселения Менделеевского муниципального района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл Җирлеге Советы |
|---|---|

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**26 март 2026 ел** **№ 21**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 августындагы 51 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында "2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы "Абалач авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Абалач авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен « Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә контракт буенча муниципаль вазыйфаларны һәм башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 4 августындагы 51 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru “Абалач авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Абалач авыл җирлеге Советы рәисе И.Н. Әкбәров